Ким авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР

№43-1 от 29.03.2022 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 сентябрь 28-1 карары белән расланган Ким авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (2021 елның 09 декабрь 37-1 номерлы үзгәрешләр белән )

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 сентябрь 28-1 карары белән расланган Ким авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (2021 елның 09 декабрь 37-1 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы абзац өстәргә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унынчы - унөченче абзацларны унберенче - ундүртенче абзацлар дип санарга.

1.2. 20 статьяның 2 өлешендә «җирлек йөкләмәләре» сүзләрен «тиешле ел ахырына файдаланылмаган бюджет кредитының инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән калдыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Ким авыл җирлеге башлыгы: В. В. Синчугов

СОВЕТ КИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ